Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 21 апрелендәге 254 номерлы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәүне (исәпкә алу) оештыру һәм гамәлгә ашыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары (Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенең 2005 елның 29 декабрендәге 164/1084–4 номерлы, 2008 елның 19 ноябрендәге 138/1017–5 номерлы, 2010 елның 22 декабрендәге 232/1517–5 номерлы һәм 2014 елның 19 февралендәге 218/1416-6 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Россия Федерациясендә сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәү (исәпкә алу) дәүләт системасы турындагы нигезләмәгә туры китерү максатларында Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәүне (исәпкә алуны) оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 21 апрелендәге 254 номерлы карарының 2.2 пунктына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.3 риур формасы буенча «сүзләрен» 1.3 риур (Нигезләмәнең 3 нче кушымтасы) «сүзләрен "1.3 риур, 1.5 риур формалары буенча" сүзләренә алмаштырырга[1] (Нигезләмәгә № 3, № 14 кушымталар)».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ш.А. Алиуллов

Хәйруллина Э. Ж.
2-20-50